РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АРТАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422069, Республика Татарстан, Сабинский район,
д.Два поля Арташ, ул. Тукая, 61
тел. (84362) 44-7-15

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АРТАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422069, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Ике басу Арташ авылы, Тукай урамы, 61 йорт
тел. (84362) 44-7-15

e-mail: Art.sab@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　КАРАР
13.11.2024　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　№ 37

Татарстан Республикасының Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлеге Башкарма комитетының 10.04.2023 елда, № 10 карары белән расланган “Хезмәт хакын түләү буенча Бердәм тариф челтәренә карамый торган аерым бюджет оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт хакын түләү шартлары турында”гы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 29 апрелендәге 287 номерлы «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф сеткасы кагылмый торган бюджет өлкәсе аерым оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфа окладлары күләмен арттыру һәм 30.03.2018 ел, №195 “Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәт хакы буенча бердәм тариф челтәре” карарына үзгәрешләр кертү нигезендә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлеге Башкарма комитеты 10.04.2023 ел, №10 “Хезмәт хакын түләү буенча Бердәм тариф челтәренә карамый торган аерым бюджет оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт хакын тәләү шартлары турында”гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карарның 1 пунктындагы дүртенче абзацында «13 323» санын «13 990» санына алыштырырга.

2. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы һәм Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлеге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/artash адресы буенча бастырып чыгарырга.

Арташ авыл җирлеге Башлыгы　　　　　　　　　　　　Р.И.Мөхәрләмов